

Быел олимпиадада Татарстан Республикасыннан - 220, чит илләр (Казахстан, Кыргызстан, Азербайжан, Үзбәкстан) укучылары һәм студентлары - 11 кеше; Россия Федерациясе субъектларынын мәгариф оешмалары һәм мәктәпләренен 8-11 сыйныф укучылары - 220 кеше, Татарстан Республикасы югары уку йортлары һәм Россия Федерациясенен башка субъектлары студентлары - 49 кеше катнашкан. Шул исәптән Мордовиядән 9 укучыны «Педагог 13. ру» методисты Фазия Фәрит кызы Боярова житәкләгән.      Халыкара олимпиадасында катнашучылар арасында Мордовиядән 9 укучы булуы да зур дәрәжә. Алар Ботенроссия олимпиадасы призерлары: Муртазина Самира белән Айзятуллов Ильнур, Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе 9 класс укучылары (укытучылары А.Ф.Муртазина).
Мансурова Ильнара белән Курмакаева Карина, Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе 9 класс укучылары (укытучылары Ф.Ф.Боярова).
Харисова Энже, Ләмберә районы Аксён урта мәктәбе 10 класс укучысы (укытучысы А.Ш.Абдюшева).
Кузикова Самира, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 11 класс укучысы (укытучысы С.С.Саляева).
Тумпарова Алсу белән Тумпарова Регина, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе 11 класс укучылары (укытучылары С.Р.Поташова).
Алькаева Римма, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе 11 класс укучысы (укытучысы Р.М.Юмаева). Әйтеп китәргә кирәк, жаны белән татар теле очен кайгырган, татар теле һәм әдәбияты буенча Татар Тавла укучыларына белем биргән Альфия Фатих кызы Муртазина да олимпиадачылар белән бергә була.
Ярышта катнашучылар 22 апрельдә Татарстаннын Крутушка бистәсендәге «Байтик» лагерендә теркәлгәч, К.Тинчурин исемендәге татар дәвләт драма һәм комедия театрында спектакль караганнар. Аннары Олимпиаданы ачу тантанасы vтә һәм Т.Миннуллин «Нәзер» спектаклен карыйлар. Ә 23 апрельдә татар теле буенча олимпиада биремнәрен vтәv (теоретик тур) була. Тошке аштан сон «ЮНЕСКО - мирас сагында» темасына проект эшләрен яклау vтә. Кич белән олимпиадачылар татарча концерт-дискотекада ял итәләр. Дискотеканы жырчы Ильшат Сафин алып бара.
24 апрельдә «Минтимер һәм анын дуслары» фильмын карап, режиссер, артистлар белән очрашу-әнгәмәдә катнашалар. Казан шәһәре буйлап экскурсиядән сон Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәвләт яшь тамашачы театрында спектакль карыйлар. Кичен «Дуслык кvпере» - торкемнәрдә тематик кичәләр vтә. Икенче конне, ягъни 25 апрельдә, олимпиадачылар «Сәйдәш» мәдәният vзәгендәге репетициядән сон «Туган тел форумы»нда катнашалар. Олимпиаданы ябу тантанасында жинvчеләрне котлау була.
«Олимпиаданын йомгаклау этабы ике турдан торды. Беренчесе - татар теле һәм әдәбияты, шулай ук татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча язма сынау. Икенчесе - телдән «ЮНЕСКО - мирас сагында» дигән темага проектлар яклау. Безнен укучыларыбыз торле темаларга (мәсәлән, Татар Тавласы, Пенза олкәсе, Болгар иле, Татарстан һәм башкалар) vзләренен проектларын якладылар», - дип сойләде Фазия Фәрит кызы.

Олимпиаданын тантаналы ябылу олешендə Татарстан Дəvлəт Советы рəисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һəм vстерv мəсьəлəлəре комиссиясе рəисе Марат Əхмəтов Татарстан Президенты Ростəм Миннеханов исеменнəн сəламлəде.
«Халыкара олимпиада - зур вакыйга. Тукаебыз исəн булса телебезнен, традициябезнен килəчəгенə омет булачагына ышанып шулкадəр соенер иде. Министрлык телебез язмышы, килəчəге очен никадəр эш башкара икəн. Һəр катнашучы - татарнын алтын баганасы», - диде ул.
Жинvчелəрне Идел буе Физик культура, спорт һəм туризм академиясендə Татарстаннын мəгариф һəм фəн министры Илсур Һадиуллин котлады. Ул: «Шунысы соендерə: ел саен катнашучылар саны арта. Биредə татар халкына мəхəббəт белəн караган, аны яраткан кешелəр жыелган», - диде Илсур Һадиуллин.
Чыннан да, Мордовия татар миллəтле балаларыбыз туган татар теллəрен халыкара кvлəмендə лаеклы кvрсəтvлəре белəн кадерле. Тугыз укучыбыз татар теле һəм əдəбиятыннан Х Халыкара олимпиадасы сертификатлары белəн кайттылар. Афəрин.

**Наилə НАСЫРОВА**